**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

20.01.2025 40-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2022 елның 28 февралендәге 155-п номерлы боерыгы белән расланган Төбәк дәүләт экология контроле кысаларында Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан кулланыла торган тикшерү кәгазе (аларга булган җаваплар контрольлектәге зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлүе яки үтәлмәве турында раслый торган тикшерү сораулары исемлеге) формасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының норматив хокукый актын Россия Федерациясе Су кодексының 65 статьясындагы 15 өлешенә һәм $67^1$ статьясындагы 3 өлешенең 3 пунктына туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Төбәк дәүләт экология контроле кысаларында Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан кулланыла торган тикшерү кәгазе (аларга булган җаваплар контрольлектәге зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлүе яки үтәлмәве турында раслый торган тикшерү сораулары исемлеге) формасын раслау турында» 2022 елның 28 февралендәге 155-п номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2022 елның 26 июлендәге 630-п номерлы, 2023 елның 13 мартындагы 256-п номерлы, 2023 елның 1 августындагы 902-п номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Төбәк дәүләт экология контроле кысаларында Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан кулланыла торган тикшерү кәгазе (аларга булган җаваплар контрольлектәге зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлүе яки үтәлмәве турында раслый торган тикшерү сораулары исемлеге) формасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

13 пунктта «тикшерү кәгазе» сүзләреннән соң «(алга таба — инспектор)» сүзләрен өстәргә;

14 пунктта:

17 нче сорауда «Мәҗбүри таләпләрнең эчтәлеген чагылдыра торган сораулар» икенче графасында «үләт базлары» сүзләрен «биологик калдыкларны юкка чыгару объектлары» сүзләренә алмаштырырга;

18 нче сорауда «Мәҗбүри таләпләрнең эчтәлеген чагылдыра торган сораулар» икенче графасында:

«үләт базлары» сүзләрен «биологик калдыкларны юкка чыгару объектлары» сүзләренә алмаштырырга;

«агулы матдәләр» сүзләрен «агулы матдәләр (исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана торган диңгез портлары территорияләрендәге аммиак, метанол, аммиак селитрасы һәм калий нитраты махсуслаштырылган саклагычларыннан тыш, яр буе яклау полосалары чикләреннән читтә)» сүзләренә алмаштырырга;

«диңгез портлары территорияләрендәге махсуслаштырылган саклагычларда» сүзләрен «диңгез портлары территорияләрендә урнаштырылган махсуслаштырылган саклагычларда» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 15 пункт өстәргә:

«15. Контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрүдә катнашучы инспекторларның, шулай ук инспекторлар төркеме җитәкчесенең имзалары (контроль (күзәтчелек) чарасын инспекторлар төркеме составында берничә инспектор үткәргән очракта)) ___________.».

2. Әлеге боерык, 2025 елның 1 мартыннан үз көченә керә торган 1 пунктның дүртенче һәм алтынчы абзацларыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары И.И.Гобәйдуллинга йөкләргә.

Министр А.В. Шадриков